Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Бима авыл җирлегенең Пеләмеш торак пунктында **ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

2019 ел, 16 октябрь №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Бима авыл җирлеге Пеләмеш торак пунктында гражданнар җыены **КАРАР БИРДЕ:**

1. I төркем инвалидларыннан, өлкән яшьтәге гражданнар (80 яшькә җиткән), көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган затлардан кала, Бима авыл җирлеге Пеләмеш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 2020 елда үзара салым акчаларын 350 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирлектә әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- Пеләмеш авылының Мәктәп урамындагы юлны ремонтлау һәм вак таш җәю.
- Пеләмеш авылын су белән тәэмин итү өчен тирән насослар һәм материаллар сатып алу, ремонтлау.
- Пеләмеш авылы урамнарын яктырту өчен яктырткычлар һәм лампалар сатып алу.
- Пеләмеш авылы урамнарын кардан чистарту.
-Янгын сүндерү автомашинасын карап тоту, ремонтлау, янгын сүндерү машинасын йөртүчегә хезмәт килешүе буенча түләү.

3. Гражданнарның җыен нәтиҗәләрен Бима авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштыру, http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм http://agryz.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Әгерҗе муниципаль районы сайтында бастыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе В.В. ШАМЕЕВ

Агрызский муниципальный район Республики Татарстан Совет Бимского сельского поселения Бима авыл җирлеге Советы ИНН 1601002621 Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы